ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_____________ с. Верхний Услон _____________

Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының торакны торак бина, торак урынны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йорт дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында.

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010нчы елның 27нче июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010нчы елның 2нче ноябрендәге 880нче номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә расларга:

Торакны торак бина, торак урынын авария хәлендәге һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йортны яшәү өчен яраксыз дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты 1нче кушымта һәм «Торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле» муниципаль хезмәт күрсәтүнең технологик схемасы 2 нче кушымта.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.С. Хакимзянов

Әзерләде һәм бастырды:
Московкин А.А. 4 экз.